КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 август г.Казань № 696

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 16 февраль, 59 нчы; 2006 ел, 7 июнь, 282 нче; 2008 ел, 5 декабрь, 858 нче; 2009 ел, 24 февраль, 98 нче; 2010 ел, 31 март, 205 нче; 2011 ел, 10 июнь, 470 нче; 2011 ел, 13 август, 673 нче; 2012 ел, 17 август, 716 нчы; 2013 ел, 7 март, 153 нче; 2013 ел, 25 ноябрь, 924 нче; 2014 ел, 7 июнь, 387 нче; 2015 ел, 27 ноябрь, 897 нче; 2016 ел, 8 апрель, 202 нче; 2016 ел, 3 август, 531 нче; 2016 ел, 24 ноябрь, 873 нче; 2017 ел, 4 июль, 459 нчы; 2017 ел, 15 ноябрь, 876 нчы; 2017 ел, 27 декабрь, 1052 нче; 2018 ел, 11 июнь, 456 нчы; 2018 ел, 24 декабрь, 1213 нче; 2018 ел, 26 декабрь, 1232 нче, 2019 ел, 22 март, 210 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг буенча комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Комитет социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы (01.15.01.1*).»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Комитет үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функцияләрен тормышка ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*);

Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы нигезендә кодны билгеләү.